# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында" Татарстан Республикасы Законының 27 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 25 ноябрендә
кабул ителде

"Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында" 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 27 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 8 (II өлеш), № 12 (X өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), түбәндәге эчтәлекле 4 һәм 5 өлешләрне өстәп, үзгәрешләр кертергә:

"4. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән гамәлләргә түбәндәгеләр керми:

1) гражданнарның гаилә әгъзаларын яшәү урыны буенча урнаштыру, әгәр урнаштырганчы алар:

а) элеккеге яшәү урыны буенча торак урыныннан мөстәкыйль файдалану хокукына ия булмаган булсалар;

б) элеккеге яшәү урыны буенча гаиләнең бер әгъзасына торак бирү нормасыннан кимрәк мәйданлы торак урыныннан социаль наем шартнамәсе буенча файдалану хокукына ия булган булсалар;

в) элеккеге яшәү урыны буенча билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип танылган торак урынына ия булган булсалар;

г) элеккеге яшәү урыны буенча торак урынын дәүләт милкенә яисә муниципаль милеккә түләүсез тапшырган булсалар;

2) гомерлек рента һәм гомерлек тәрбиядә тоту шартнамәсен рента алучы инициативасы белән өзү, торак урынын рента алучыга кире кайтарып;

3) торак урынын сату-алу шартнамәсен суд тәртибендә гамәлгә яраксыз дип тану.

5. Торак урынына мохтаҗ буларак исәптә тору хокукын алу максатларында гражданның үз торак шартларын начарайту нияте, әгәр үз көченә кергән суд карары белән башкасы билгеләнмәгән булса, әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән гамәлләрне кылган көннән алып биш ел үткәнчегә кадәр исәпкә алу турында гариза белән мөрәҗәгать итү факты буенча билгеләнә.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2011 елның 13 декабре
№ 101-ТРЗ